СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2023 г.Зеленодольск № 340

Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган шәһәр һәм авыл җирлекләренә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган шәһәр һәм авыл җирлекләренә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы вәкаләтләренең бер өлешен 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче кушымталарында каралганча тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләренең бер өлешен шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешүләр төзергә,1 нче , 2 нче,3 нче, 4 нче, 5 нче кушымталарда күрсәтелгән.

3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру 1 нче, 2 нче,3 нче, 4 нче, 5 нче кушымталарында күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетына Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган финанс чаралары хисабына башкарыла.

4. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы

Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы,Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2023
елның 23 ноябрендәге 340
номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итә торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Әйшә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә :**

- ПСД эшләү:«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Әйшә авылында Тын һәм Кооператив урамнары тирәсендәге күлләрне чистарту».

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2023
елның 23 ноябрендәге 340
номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итә торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Акъегет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә :**

- ПСД эшләү: «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бакырчы авылында Әрә елгасының уң кушылдыгы юлын чистарту».

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2023
елның 23 ноябрендәге 340
номерлы карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итә торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенә: :**

- Зеленодольск районы Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогында НРО урыннарын бетерү.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2023
елның 23 ноябрендәге 340
номерлы карарына
4 нче кушымта

**Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итә торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Октябрь авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенә:**

- ПСД эшләү: «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Октябрьский п. Тимер Юл, Пионер, Беренче Май урамнарындагы күлләрне чистарту».

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2023
елның 23 ноябрендәге 340
номерлы карарына
5 нче кушымта

**Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итә торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Осиново авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенә:**

ПСД эшләү: «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Пионер» ДОЛ янындагы Сухая елгасының сулъяк кушылдыгындагы тугай күлне чистарту».